ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Школьная, д.1 , д. Смак Корса, Арский
муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мэктэп ур, 1 нче йорт, Курса Почпак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366) 53-2-36 факс (84366) 53-2-36. E-mail Smk.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от « 17 » декабря 2025 г.** **№ 89**

**Арча муниципаль районы "Сеҗе авыл җирлеге"
муниципаль берәмлегендә гражданнардан
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 04 августындагы 63 номерлы Сеҗе авыл җирлеге Советы карары нигезендә, 08.11.2025 N 3,4, 10.11.2025 N 5, 17.11.2025 N 6,7, 18.11.2025 N 8, 19.11.2025 N 9,10, 20.11.2025 N 11,12,13, 22.11.2025 № 12,24.11.20245 №13,25.11.2025 №14,26.11.2025 №15 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы "Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. "Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында" 2024 елның 10 декабрендәге 39 номерлы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Курса Почмак авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Сикертән авылы,Үзәк урам,14 йорт,Татарстан Республикасы,Арча районы,Сеҗе авылы Мәктәп урамы,25 йорт.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемә алам.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хамидулли

Сеҗе авыл җирлеге
башкарма комитетының
17.12.2025 ел, № 89
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы "Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районы "Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районы "Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2026 елның 26 февраленә кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир яки хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге бүлектә белем алучы студентлар,

б)1 группа инвалидлар

в) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен,

түләүләр күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (ата-анасының, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы,

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында гражданнарга хәбәр итү бланкы (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгару, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районы "Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча

күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгәндә, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Сеҗе авыл җирлеге
башкарма комитетының
17.12.2025 ел, № 89
карарына 2 нче кушымта

Сеҗе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә N ______________

Түләүченең Ф.И.А.и________________________________________

Адресы:________________________________________________

Нигезе__________________________________________________

Сезгә ________ чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләү_______________суммада _______ сум түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:__________________________

алучының банкы БИК _________________________

Сч. N __________________________________

Алучы Сч. N __________________________

ИНН _____________________________________

КПП _____________________________________

КБК _______________ОКАТО ________________

Түләүнең билгеләнеше _________________________________

Җитәкче _______________ ________________________________

М. у. (имза) (имзаның аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисем сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

"Сеҗе авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә №__
суммада _______________ сум

Түләүченең Ф. и.а.и. ___________________________________

Адресы: ___________________________________________

Алдым "___" ______________ 20__ ел __________________________

(түләүченең имзасы /ФИАи)

Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек тамыр тутырыла һәм Сеҗе авыл җирлеге Башкарма комитетында кала